**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«25» 10 2021 ел Яр Чаллы № 129

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегенең 16:39:021201:4801 кадастр номерлы җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен төп төрдән шартлы-рөхсәт ителгән төргә үзгәртү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 35, 36, 39 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»131-ФЗ номерлы Федераль закон, Тукай муниципаль районының Әҗмәкәй авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре, район уставы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2018 елның 29 декабрендәге вн/2 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районында халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә, район һәм Әҗмәкәй авыл җирлеге халкының уңайлы тормыш шартларына хокукларын, Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатыннан,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегенең 16:39:021201:4801 кадастр номерлы җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен «Торак төзелеше өчен» төп төрдән «Магазиннар» шартлы-рөхсәт ителгән төргә үзгәртү буенча халык тыңлауларын.

2.1. Әлеге карарны районның рәсми сайтында (tukay.tatar.ru) һәм Әҗмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитетының мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

2.2. Халык тыңлауларын үткәрү турында мәгълүматны «Якты Юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга.

3. Халык тыңлауларын бер көндә, 2021 елның 29 ноябрендә 15.00 сәгатьтә үткәрергә, үткәрү урыны: Тукай районы, Әҗмәкәй авыл җирлеге, Яңа пос., Үзәк урамы, 1.

4. Халык тыңлауларын үткәрү өчен җаваплы итеп Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге башлыгы урынбасары О.А. Никитинаны билгеләргә.

5. Проект буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен кушымта нигезендә расларга.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Тука муниципаль район Башлыгы Ф.М. Камаев